| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>ЯР БУЕ МОРКВАШЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| РЕШЕНИЕ<br>19.12.2022 | с. Набережные Моркваши | КАРАР<br>№ 29-172 |

Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә, җирле салымнар һәм җыемнар буенча бурычларны түләтүгә ышанычсызлыкны җайга салу максаты белән,

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Җирле салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә вафат булган көннән алып 6 ай дәвамында мираска алынмаган очракта вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

2) оешмалар яисә индивидуаль эшкуарлар тарафыннан 2022 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган җирле салымнар буенча исәпләнелә торган недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу;

3) салым исәбенә куелган һәм юридик затларның Бердәм дәүләт реестрында үзләренә карата мәгълүмат булмаган оешмаларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

4) Россия Федерациясе законнары нигезендә бетерелгән оешмаларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу;

5) “Башкару эшчәнлеге турында” 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 һәм 4 пунктларында каралган нигезләрдә башкарма производствоны тәмамлау турындагы карарны үтәтү приставы-башкаручы чыгарган очракта, салым органнары тарафыннан әлеге недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтү мөмкин булмаган очракта, бөлгенлек (банкротлык) турындагы эштә кулланыла торган процедураларда булмаган салым түләүчеләрдә недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу;

6) үзләре исәпләгән недоимка булмаса, шушы недоимканы түләтү срогы тәмамланганнан соң недоимкага исәпләнгән оешмаларның пенялар буенча бурычы булу;

7) суд тәртибендә хокуктан файдаланугa сәләтсез дип танылган психик тайпылышлары булган затлар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч булу;

8) Россия Федерациясеннән киткән физик затларның недоимкасы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычы булу, аны түләү 3 елдан артык узган вакыттан алып, бурычлының түләтү алынырга мөмкин булган мөлкәте булмаганда.

2. «Җирле салымнар буенча недоимканы, пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2019 елның 28 октябрендәге 81-350 номерлы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы _______ И.Х.Гаязов